**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5525

ТР Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.

2. ТР Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.

3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 12 октябрендәге 3435 номерлы карары, 2024 елның 23 январендәге 173 карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5525 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә

бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1. | «Рус сүзе» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
«Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры ____________ В.В. Сәфиуллина

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ____________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Рус сүзе»** - рус теленең сүз составын тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерелгән. Укучылар, лексика белән шөгыльләнеп, сөйләм культурасын арттыралар, белешмә әдәбиятыннан файдалана беләләр. Дәресләрдә балаларның сүзлек һәм фразеологик запасы баетыла.

Әлеге хезмәт 14 яшьтән 16 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 52 кв.м., балалар саны - 20.

ТР Тукай муниципаль районы
«Түбән Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры ________________ В.В. Сәфиуллина